КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 август г.Казань № 570

2017 елда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга булышлык күрсәтү» грантларын бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2017 елда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга булышлык күрсәтү» грантларын бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 14 август, 570 нче
карары белән расланды

2017 елда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга булышлык күрсәтү» грантларын бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип мәгариф эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итүче сәләтле балалар өчен интернаты булган мәгариф оешмаларына 2017 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга булышлык күрсәтү» грантларын (алга таба – грантлар) бирүне регламентлаштыра.

2. Субсидияләр рәвешендә грантлар бирү «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) грантлар бирү өчен расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлекләрен алып барган милекнең барлык төрләрендәге мәгариф оешмалары грант алучылар булып тора (алга таба – грант алучылар), аларга карата Министрлык гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарган мәгариф оешмаларыннан һәм муниципаль гомуми белем бирүче оешмалардан тыш.

4. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга олимпиада клублары эшчәнлеген булдыруга һәм оештыруга юнәлтелгән булышлык күрсәтү грант бирүнең максаты булып тора.

5. Грантлар «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәләтле балалар өчен интернат тибындагы махсуслашкан оешмаларга булышлык күрсәтү» грантларын бирүгә конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – конкурс нигезендә сайлап алу) нәтиҗәләре буенча бирелә.

6. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийләре түбәндәгеләр:

мәгариф оешмалары эшчәнлеге күрсәткечләре, үз методик эшләнмәсе булу;

мәгариф оешмасы алдында куелган бурычларны исәпкә алып, олимпиада клубы эшчәнлеге юнәлешләренең актуальлеге, яңалыгы, максатка ярашлы булуы;

олимпиада клубы эшчәнлеген оештыру өчен беренчел база булу;

олимпиада клубы эшчәнлеген гамәлдә тормышка ашыруның нәтиҗәләре фаразы.

Конкурс нигезендә сайлап алу критерийләре күрсәткечләре мәгънәләрен Министрлык билгели.

7. Грант акчасы түбәндәгеләргә юнәлтелә:

олимпиада клублары эшен оештыруга, олимпиада әзерлеге профиле буенча уку-тренировка җыеннарында укучыларны әзерләүне дә кертеп (юлда йөрү, туклану, яшәү, оештыру җыемы (кертем));

мәгариф оешмалары педагоглары коллективын һөнәри үстерү һәм квалификация күтәрү, мәктәп укучылары арасында олимпиада хәрәкәтен тарату өлешендә мәгариф оешмаларының эш тәҗрибәсен өйрәнү буенча семинарлар оештыру;

мәктәп укучыларын бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге олимпиадаларга, интеллектуаль конкурсларга һәм ярышларга әзерләгәндә мәгариф оешмаларының матди-техник базасын камилләштерү;

укучыларның бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге интеллектуаль конкурсларда һәм ярышларда катнашуы нәтиҗәләре буенча педагоглар коллективын матди бүләкләү.

8. Грант максатчан билгеләнешкә ия һәм грант алучы тарафыннан әлеге тәртиптә каралмаган максатларга файдаланыла алмый.

9. Әлеге Тәртип нигезендә түбәндәгеләр бирелә:

2 200 000 сум күләмендә 2 грант,

2 100 000 сум күләмендә 4 грант,

1 800 000 сум күләмендә 3 грант,

1 500 000 сум күләмендә 2 грант.

10. Грант Министрлык белән конкурс нигезендә сайлап алуы җиңүчесе арасында төзелгән грант бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә, конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләрне ясаган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә бирелә. Шартнамә формасын һәм аны төзү вакытларын Министрлык раслый.

Шартнамәдә түбәндәге нигезләмәләр карала:

грантның максатчан билгеләнеше;

гранттан файдалану юнәлешләре;

грантның күләме;

грант бирүнең нәтиҗәлеге күрсәткечләре мәгънәсе;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, шулай ук грант бирүнең нәтиҗәлеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында хисап бирү тәртибе һәм вакыты;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавын тикшерүгә ризалык;

грантны алганнан соң 18 ай эчендә файдаланмаган грантны кире кайтару тәртибе;

шартнамә нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык.

11. Грантлар шартнамәдә каралган вакытларда конкурс нигезендә сайлап алу җиңүчеләренең кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерелә.

12. Грант алучылар шартнамәдә билгеләнгән формалар буенча һәм вакытларда Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны

гамәлгә ашыру турында хисап, шулай ук грант бирүнең нәтиҗәлеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында хисап тапшыра.

13. Грантлар бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларын һәм шартларын бозу фактлары билгеле булган очракта бирелгән грантлар министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

14. Грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше грант алучы тарафыннан шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән акчаны ирекле рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарудан баш тартылган очракта алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә кайтарылырга тиеш.

16. Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучыларның грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавын тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган, шулай ук конкурска тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә грант алучыга йөкләнә.

18. Бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.